| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

22.10.2019 Алабуга шәһәре № 404

**2018 елның 13 декабрендә чыккан 311 санлы «Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлегенең 2019 елга һәм 2020, 2021 елларның планлы чорына бюджеты турында» гы Алабуга муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Алабуга муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмә нигезендә һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 83 һәм 86 маддәләренә таянып, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАРАР кабул итте:

1. 2018 елның 13 декабрендә чыккан 311 санлы «Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлегенең 2019 елга һәм 2020, 2021 елларның планлы чорына бюджеты турында» гы Алабуга муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 1 маддәдә:

*1 өлешендә*

1 пунктта «1 703 634,7» саннарын «1 762 639,0» саннарына алмаштырырга;

2 пунктта «1 865 603,9» саннарын «1 925 308,2» саннарына алмаштырырга;

3 пунктта «161 969,2» саннарын «162 669,2» саннарына алмаштырырга.

*3 өлешендә*

"2019 елга район Бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары» дигән 1 нче кушымтадагы 1 нче таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә.

2) 3 маддәдә:

«2019 елга район Бюджетының фаразлана торган керемнәре күләмнәре» дигән 2 нче кушымтадагы 1 нче таблицаны кертелә торган үзгәрешләр өлешендә бәян итәргә.

3) 6 маддәдә:

«Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең югары дәрәҗәдәге баш администраторлар исемлеге» дигән 4 нче кушымтага үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

4) 7 маддәдә:

«2019 елга район бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» 6 кушымтасында 1 нче таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә;

«2019 елга Алабуга муниципаль районы Бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бүлекләр һәм бүлекчәләр, максатчан маддәләр (Алабуга муниципаль районы муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программалы булмаган юнәлешләре), бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү» дигән 7 нче кушымтадагы 1 таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә.

«2019 елга район Бюджетының бюджет ассигнованиеләрен максатчан маддәләргә (Алабуга муниципаль районы муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программалы булмаган юнәлешләре), бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләр һәм бүлекчәләргә, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү» дигән 8 нче кушымтадагы 1 нче таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә.

5) 14 маддәдә

«2019 елга җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен җирлекләр бюджетларыннан муниципаль район бюджетына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» турындагы 12 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.

6) 15 маддәдә

«2019 елга өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен җирлекләр бюджетларына бирелә торган бюджетара трансфертлар» дигән 13 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны икътисадый үсеш, бюджет, салымнар, тариф сәясәте, эшкуарлыкка һәм туризмга ярдәм итү мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Рәис урынбасары З.Х. Сөнгәтуллина